СОВЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
«05» октябрь 2023ел

КАРАР
№ 132

«Татарстан Республикасының Зеленодол муниципаль районы «Норлат авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» гы Норлат авыл җирлеге Советы 01 ноябрь 2019 ел №199 карарына (Нурлат авыл җирлеге Советының 2020 елның 13 ноябрендәге 12 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясенең аерым закон актлары һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлеше 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында», Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Норлат авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Норлат авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасының Зеленодол муниципаль районы «Норлат авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» гы Норлат авыл җирлеге Советы 01 ноябрь 2019 ел №199 карарына (Нурлат авыл җирлеге Советының 2020 елның 13 ноябрендәге 12 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.2 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. 0,3% торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килгән яки сатып алынган (бирелгән) җир участогы өлешеннән тыш) торак төзелеше өчен (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, 2019 елның 1 декабренә кадәр Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru, шулай ук Нурлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Заволжье " ЦКС бинасы). урнаштырырга.

Норлат авыл жирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.М.Саттаров